


Чаян

СКОРПИОН

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ* АПРЕЛЬ * 2016 КАЗАН

7

ISSN 0136-7110



АННАН-МОННАН ИНФОРМ

СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

- Халыкара валюта фонды (МВФ) Порошенконы ел теләнчесе дип таныды.
- Дональд Трамп, президентлыкка сайлауларда җиңгәннән соң, канында мельдоний барлыгы ачыкланудан шикләнә. Чөнки бу очракта җиңү дөрес дип саналмаячак.
- Сәясәтчеләр бер фикердә: Кырымны ил составына керткәннән соң, Путинга Үзәк банкны да Россиягә кушарга кирәк булачак.
- HeadHunterда "АКШ президенты" вакансиясе барлыкка килгән.
- Финанс белгечләре бар булган әйберләрне метро жетонына туплап кулланырга киңәш итәләр.
- Депутатлыкка кандидат, сайлаучыларны тагын бер биш елдан Европадагы кешеләр кебек яшиячәксез, дип куркыткан.
- Сенсация: Интернеттагы теләсә кем төшереп куела торган популяр роликларны Голливуд павильоннарында төшерәләр икән.
- Россия спутникларының Украина күгеннән очып үткәннәре өчен түләү кертелгәч, Майдан активистларын безнең космик аппаратларны чик буенда туктата башлаганнар.
- Мик Джаггер һәм Led Zeppelin Юрий Лозадан мастер-класс бирүне сораганнар.
- Симерүдән котылуның иң яхшы чарасы дип ашамлыкларның бәяләре кыйммәт булуы танылган.
- Дагстанда, светофор төбендә машинасы яшел ут кабынганын бик озак көтеп торган чит ил шпионын тотканнар.
- Галимнәр, докторлык диссертациясен яклаган банкеттан соң бер коллегаларының күз төбендә барлыкка килгән сәер тапларын өйрәнәләр.
- Яңа айфон турындагы шаяртулар алдагы төрттерел сөйләшүләргә караганда шаянрак килеп чыккан.
- "Криминал яңалыклар" телесериалында катнашу өчен кастинг үткәрү игълан ителгән.
- Инглиз галимнәре ачыклаган, ләкин анык кына нәрсә икәнен аңлата алмаган.

Виталий ФЕОКТИСТОВ





ШОМБАЙ болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Соңгы вакытта бездә "дәрәҗәле" нәчәлникләр үрчеп китте. Кайсы гына башлыкны алма – ниндидер фәннәр кандидаты, йә докторы. Ике сүз бәйли алмый, ә үзе, карагыз – галим! Алар өчен "диссертация"ләрнең ничек язылуын бөтен кеше бик яхшы белә. Ул "галим"нәрне плагиатта ничә тапкыр тоттылар бит инде! Кулымнан килсә, мин аларны берничә елга "фәнни командировка"га – зонага җибәрер идем...

М. ШӘРИПОВ

БӨГЕЛМӘ

Ә мин аларга карата катырак булыр идем, – диде Шомбай ага, укучының хатын укып чыккач. **– Үз диссертацияләрен укып чыгарга мәҗбүр итәр идем...**



Николай ВОРОНЦОВ



«Ат җегәре» («Лошадиная сила») шампуненнан чәч күзгә күренеп үсә!

(телереклама)

Айныткыч махсус хезмәт күрсәтүгә ябык (туй).

Россия җитештерүчеләренең импорт аяк киемнәрен сату.

4 шешә аракы сатып алганнарга бүләккә сыерчык оясы!

Бакчачылар җәмгыятенә атарга лицензиясе булган сакчы кирәк.

Туй букетлары. Даими клиентларга ташламалар.

(белдерүләр)

Краснодар дөгесе (Кытай).

Ташламалар. Хатын-кыз трусиклары. 1 килограммы – 680 сум.

(бәянамәләр)

Рөстәм ЗАРИПОВ

КРИЗИС

...Министрлар һәм дә депутатлар,
Өстәмә эш эшләп, ризык таба,
Рекламалый тортлар, сөт һәм сыра,
Кайсы бөтерелә стриптиз-барда...

Кайсы туалетка билет сата,
Кәгазь биреп тора теләүчегә;
Яшьрәкләр юл чатына чыккан, –
Утырып китәләр, түләүчегә...

Аннан алар тишек тиеннәрен
Юл читенә чыгып санап торыр...
Кризис турында җыру чыкса,
Шундыйрак клип ярап торыр;

...Ә хагында кризис авторлары
Гаҗиз бүген, бар да аптырашта;
Су язып күп май чыгарды алар,
Кайсы салдый, кайсы аек баштан...

...Бу да исләнде, дип, чүрәкәй кош,
Ташлый, имеш, чираттагы күлен;
Үзе сасытканын аңламыйча,
Сафлык эзли, имеш, көне-төне...

Түрәкәйләр дә шул чүрәкәй күк,
Илне батырдылар кризиска;
Ярый ла тончыгып үлмәсәләр,
Үзләре чыгарган хәсис искә...



Сергей ЕРМИЛОВ

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР

Хатыннар – музыкаль инструментлар кебек: аларның яңгырашы кемнең һәм ничек кагылуыннан тора.

Үз теләгең белән берәр нәрсә эшләп кара – икенче тапкыр синнән аны көтәчәкләр, өченче тапкыр – таләп итәчәкләр.

Әгәр хатын-кыз бай ирдән баш тарткан икән, димәк, ул кадәр үк бай түгел...

Әгәр телевизордан атыш-куышлар, катастрофалар һәм кризис юк икән, димәк, сез реклама карыйсыз.

Тәҗрибәле хатын – ул тәҗрибәсез булып кылана белүче хатын.

Бөтен дөньяда премиягә лаек булыр өчен, бездә генә премиядән мәхрүм итмәсеннәр өчен эшлиләр.

Хатыннар гына ике айлык хезмәт хакына алдан уйлый беләләр.

Әгәр акыллы да, җүләр дә бернәрсә әйтми икән, аларны бер-берсеннән аерып булмый.

(Зыялылар мәҗлесендә язып алынды)



Ринат АБЗАЛОВ

"ИМӘННӘР ШАУЛЫЙ"

Ни дисәң дә, ярата безнең халык эчәргә. Салырга, бушатып куярга, тамак чылатырга. Һәм ул эчемлекнең кырык градуслысын артыграк күрә. Ләкин бетмәс-төкәнмәс кризислар тормышка үз төзәтмәләрен кертә тора. Бүгенге көндә эчәргә яратучы халык даирәләрендә составында спирт булган дарулар һәм лосьоннар – “фанфурик”лар популярлык казанды.

Аларның ассортименты бик киң. Монда сиңа дуләнә (боярышник) һәм имән кайрысы, каен бөреләре төнәтмәләре дисеңме, легендар “Трояр” һәм башкалар... Шунысы кызык, ишегалдының кичке каһарманнары ул эчемлекләрне берберсеннән аера белә, хәтта ис-тәменә тәфсилләп бәя бирә ала.

– «Трояр» эчү өчен артык каты... – дип бүлешә үз тәэсирләре белән күрше подъездда яшәүче шәмәхә борынлы дегустатор. – Ә “Хлебный” лосьоны авызны камаштыра... Иң шәп тәм дуләнә төнәтмәсендә... Бу мәсьәләдә минем тәҗрибә җитәрлек!

100 граммлы кечкенә шешәнең уртача бәясе 15 сумнан артмый. Шуңа күрә мондый продукцияне мәшәкатьсез генә юнәтеп була торган урыннарда халык өзелеп тормый – исерткеч “дару”ларга рецепт кирәкми бит. Ләкин арзан зарарсыз булмас, диләр бит халыкта. Мондый “дәвалану”ның бик тә күңелсез нәтиҗәләргә китерүе мөмкин бит...

Ә бу мәсьәләгә сәүдә итүчеләр үзләре ничек карый соң? Аларның фикере – бушаган шешә кебек – гади.

– Ә нишләп безгә аларны сатарга ярамасын, ди? – дип гаҗәпләнде чын күңеленнән “технопарк”ларның берсендә урнашкан ларёк хуҗасы. – Ул сыекчалар эчү өчен түгел бит. Болар турында куллану инструкциясендә дә язылган. Ә сыекчаны кемнең ничек файдалануы – анысы инде безнең кайгы түгел...

Соңгы елларда “фанфурик”лар, кем әйтмешли, бөтен фронтлар буенча һөҗүмгә күчте. ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе белдерүенчә, алар инде контрафакт спиртлы эчемлекләр белән сәүдә итүнең биштән берен яулап алган. Ә менә сәүдәгәрләргә каршы, штрафка тартудан башка, бернинди дә чара юк – закон рөхсәт итми. Бу өлкәне дәүләт дәрәҗәсендә тәртипкә кертү һәм төнәтмәләрне алкоголь продукциясе дип тану тикшерүләр һәм яраштыру стадиясендә “спиртлап” куелган.

Ә халыкны агулау юлында законлы киртәләр икән, республикада бу яман белән ничек булдыралар, шулай көрәшәләр. Даими рәвештә сыекчаның зур партияләре кулланудан алына. Мәсәлән, узган ел 18 тоннадан артык продукция юкка чыгарылды. Өстәвенә, “Халык контроле” мәгълүмат системасында “Этил спирты һәм составында спирт булган продукцияне законсыз җитештерү һәм әйләнешкә кертү” бүлеге булдырылды. Һәм быелдан мондый фактлар турында хәбәр иткән гражданнарга хәтта акчалата түләү тиеш...

Һәм ахырда бераз статистика турында. Әйтергә кирәк, кызыклы нәрсә – бигрәк тә “исерек” статистика. Аннан алынган мәгълүмат буенча Россиядә яшәүче һәр кешегә 11,5 литр спирт туры килә. Әгәр моннан эчми торган ир һәм хатыннарны, балалар белән авыруларны чыгарып ташласаң, шикләнмичә бу сан икеләтә арта. Ә спиртны аракы хәленә кадәр “сыеклатсаң” – гомумән, коточкыч саннар килеп чыга. Моның әле легаль спирт кына икәнен истә тотарга кирәк. Ә монда имән кайрысы төнәтмәсе ише сыекчаларны да кертсәк – монысы инде бернинди статистикага бирелми...

Аракы – арыш мае, эч әле, карышма әле! Теләмисеңме? Барыбер эч!

Валерий СЕДЫХ

Александр АЛЁШИН



Валерий ТАРАСЕНКО



Виктор ФЁДОРОВ



Игорь ӘХМӘТҖАНОВ





• • •

Хәбәрче:

– Хөрмәтле министр, безнең гәҗиткә интервью бирмәссез микән?

– Минем һәр минутым – акча!

– Аңлыйм, менә редакция бу эшкә 100 мең билгеләде. Әйдәгез, килешик, 80 ен үзегезгә аласыз, ә миңа – 20 се, ләкин 100 меңенә кул куярга тиеш буласыз.

– Риза. Ә әңгәмәбезнең темасы нинди?

– Ришвәтчелек. “Мин – сиңа, син – миңа” турында.

• • •

Дәүләт Думасы рәсәйлеләргә укып алган һөнәрләре буенча гына эшләргә рөхсәт итмәкче була. Кызык, ә нинди уку йорты депутатлар әзерли икән?

• • •

Шансон җырларын тыңласаң, күңелдә шундый фикер туа: төрмә – шундый шәп җир икән. Анда гел талантлы кешеләр генә утыра, барысы да белемле һәм андагылар барысы да әниләрен ярата.

• • •

Урта гасырдагы спам. XV гасырда принц үзенең сөеклесеннән хәбәр көтә. Көтә-көтә өч көн, өч төн үтә. Ниһаять, почта ташый торган күгәрчен килә. Бәхетеннән нишләргә белмәгән принц хатны ачып укый, ә анда “Кылыч коям... кыйбат түгел” дип язылган.

• • •

Бер түрәнең фатирын талаганнар. Аның бернәрсәсе дә югалмаган. Ә менә эшсез хатынының 2 миллион долларын урлаганнар.

• • •

Ике бомж сөйләшә.

– Ишеттеңме, илдә кризис!

– Ничек инде ул алай?

– Синең таныш предпринимательләрең бармы?

– Юк.

– Хәзер булыр.

• • •

– Кафель плиткаларын стенага ябыштырыр өчен пластик крестиклар бармы?

– Билгеле, бар.

– Биш меңне бирегез әле...

– Шулкадәр нәрсәгә ул?

– Шефымның умарта кортлары үлде – шуларны христиан йоласы буенча җирләргә кушты.




БАЛЫКЧЫЛАРГА ҺӘЙКӘЛ

“Күнекмә”ләребездә нинди генә сәер һәм маҗаралы рәсемнәр булмады, ләкин менә мондыен әле күргәнебез юк иде. Кызык нәрсә әллә ниләр китереп чыгара бит ул. Әйтик, фантазияне көчәйтә, уй-фикерләрне куерта, төрттереп, күпертеп язасы килә: кайбер тасвирлауларга ышанырга да белмәссең... Әмма, шуларны төсмерләп, келдер-келдер көлеп утырасың. Менә бу “Күнекмә”гә аеруча көчле җавап-шаяртулар алдык. Шатландыра...

“Икенче шешәсе, ачылмаган килеш, төпкә киткән, шуны эзли”, – шулай дип язып җибәргән Балтачтагы дустыбыз, күптәнге “Чаян”чыбыз – Рәхимов Әхәт. **“Элек сәрхушләребез: “Кабан күле шулпа булып, күктән пилмән яусачы”, – дип җырлыйлар иде, бу салкын “уха” чөмерә түгелме соң?”** – Менә бит нинди уйдырмага этәргән Казан кешесен – Галим Җаббаровны әлеге рәсем. **“Качыйм әле хатыннан, таный алмас артымнан...”** Шигъри шундый шаярту да бар. Монысын безгә Яшел Үзәннән Сәгыйть әфәнде юллаган. **“Чаян” күнекмәсенә эләгү өчен ни генә кыланмыйлар!”** – дип гаҗәпләнә Түбән Новгородтагы Лысково шәһәрендә яшәүче С. Гомозов. **“Эчә-эчә башы кызган”**, – ди Әгерҗедән безне даими укучы Галимә Сабитова. **“Сәрхушкә акылга кил, намазга бас дисәң, башы белән боз ватса вата, ләкин тәүбәгә килмәс”,** – дип катгый карар чыгарган Чаллыда яшәүче ханым Гөлия Бәйрәмова. Үзәгенә үткән ирен мисалга алып әйтүедер инде. **“Ихтиандр, өченче буласың килмиме?”** – Күрәсең, боз өстендә моның белән кәеф-сафа корырга теләүче булмаганга, заманында бик популяр фильм героен искә төшереп, боз астына кычкыруыдыр инде бу адәм затының. Шуны уйлап шундый җавап язган, ахрысы, Әгерҗедән – Е. Кривошеев. **“Эчмә, Иван җаныкаем, дуңгыз буласың бит!”** – дип үтенә Әлмәттән Х. Камалова. Менә Пермь өлкәсендә безнең журналны һич калдырмый укып баручы Л. Красикова: **“Әллә боз, әллә башым чатный...”** дигән вариант тәкъдим иткән. **“Чиләбе метеориты”, –** дип мәсхәрәләү билгеләгән әлеге суртәкә Менделеев шәһәреннән П. Юргина. **“Сәрхуш балыкчыларга – һәйкәл!”** – Менә, ичмасам, җавап! Шәп эләктергәнсең, иптәш Әсхәт Гарипов! Бүтән шаяртуларны инде язып тормасаң да була! Түбән Камада яшәвең юкка түгел икән – шаяннарның анда күплеге безгә мәгълүм. Инде киләсе “Күнекмә”дә дә Әсхәт Гарипов кебегрәк үткенлектә шаяртып алыйк әле, җәмәгать!







МАЙМЫЛ ТУРЫНДА МӘЗӘКЛӘР

Маймыл, елга ярына утырып, банан кабыкларын суда җебетә. Янына крокодил йөзеп килә.

– Әй, маймыл, нишлисең син?

– 100 сум бирсәң әйтәм.

Крокодил 100 сум акча биргәч, маймыл аны алып куя.

– Банан кабыгын суда җебетәм.

– Юләрнең юләре инде син, маймыл!

– Юләр булсам да, көнгә 5000 сум җыела...

• • •

Африка саваннасында берәү скрипкада уйный. Бер арыслан, аның янына килеп, сихри музыканы тыңлый башлый. Бераздан тагын ике арыслан килеп, җиргә ятып, скрипкада уйнаучының көен әсәрләнеп тыңлый. Каяндыр дүртенче арыслан килеп чыга да, уйнаучыны буып атып, аны тәмләп ашый башлый.

– Саңгырау килгәннән соң, музыканың бетәчәге турында әйттем бит сиңа, – ди сузылып яткан арыслан күршесенә...

• • •

Тирән итеп казылган чокырга арыслан егылып төшә. Аның янында гына үскән агач башында маймыл, кулларын чәбәкләп:

– Эләктеңме, хайван! Шул кирәк сиңа! Бераздан тырнакларыңнан муенса ясармын, тешләреңнән – сувенир, тиреңне коридорга җәярмен, – ди.

Сикерә торгач, ботак сынып китә дә, маймыл арыслан янына егылып төшә. Торып кагынганнан соң:

– Арыслан-дускаем, ышанасыңмы, синең яныңа гафу үтенергә төштем, – ди.

• • •

Маймыл урман буйлап бара:

– Кризис, кризис! – дип кычкырып чаба. Каршысына очраган бүре:

– Ник акырасың, юләр, мин итне элек ничек ашаган булсам, хәзер дә шулай ашыйм, – ди.

Маймыл кычкырып чабуын дәвам итә. Каршысына төлке килә.

– Ник акырасың, юләр, мин элек тә тун киеп йөри идем, хәзер дә шулай, – ди.

Маймыл туктап кала һәм уйлана башлый...

– Дөрестән дә, нигә кычкырам соң, элек тә ялангач арт белән йөри идем, аннары да шулай йөриячәкмен, – ди.

Нияз БИШБАЛТА тупланмасыннан.

Валерий ТАРАСЕНКО





Олег ГУЦОЛ

Хәрефҗан ТЕЛЧӘНБАЕВ

КАЗАН СӨЙЛӘМ ТЕЛЕНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

"Һәр шәһәрнең – үз холкы" – дигән әйтем бар. Безнең көннәрдә әлеге аермалык байтак калаларның сөйләм телендә чагыла. Мәскәүлеләрнең сөйләшүләренә колак салыйк. Мәскәүдәнме син, дип сорасаң, ул: "Ма-а-сквич", – дип җавап бирәчәк, ә инде питердагылар белән әңгәмә корырга туры килсә, синең "булошный"лары һәм "шаверма"ларына колагың сагаеп торачак. Казанда да үзенчәлекле үзара аңлашу ысуллары бар.

Казан татары, үзенең сораулы җөмләсе ахырына "ы-ымы?" дип өстәм куя. Ә русча сөйләшүчесе "что-ли" ди. Мәсәлән: "Ты в магазин не ходила что-ли?" Татарыбыз: Син кибеткә бармадың бугай, ы-ымы?"

Русларыбызда һәр сорауга җавап сүзе сузылып әйтелә. "Нет з-а-а-чем". Мәсәлән: "Нет з-а-а-чем, ходила в магазин, просто он был закрыт!" Ә татарларыбызның болайрак – "Ни бит..." дигән сүз кулланып алына. Мисалга шул ук җөмлә: "Ни бит, барганыем да кибеткә ябык ие". Әле монда "ыем" белән "ие" дә кушыла. "Бит" дигәне – ул безнең калада ике сүзнең берендә.

Әгәр дә инде җөмләнең ахырында русларда "уж" куелса, ул җөмләдәге фикер ныгаеп китә. "Нет, з-а-а-чем, ходила в магазин, просто он был закрыт уж!"

Урысның "просто" дигән сүзенә тукталыйк әле. Аны казанлылар "но" теркәгече урынына кулланалар. Ә безнекеләр "ниткән" дип кенә җыпыртып китсәләр дә, аңлашалар.

Инде сорауларга җавап биргәндә акыллырак күренәсе килсәләр, "нет з-а-а-чем" урынына "на самом деле" сүтезмәсе кулланырга була. Мәсәлән: "На самом деле я ходила в магазин". Ә без татарча: "Ни, нитеп кайттым кибеттән". Бетте-китте, аңлыйбыз бер-беребезне.

Берәрсен үгетләп инандырырга туры килсә, урысларыбыз "считай" сүзен кыстырып куялар. Шуны теләсә кайда катнаштырып сөйләшсәң була. Татарстанда хәзер шушы сүз кебек, кирәксә-кирәкмәсә, шаяртыбрак әйтелә торган "без булдырабыз!" дигән сүз бар. Акцент белән булса да урыслар да аны яңгыратырга ярата.

"Айда" дигән Казан сүзе инде кадими заманнардан бирле кулланышта. Монысы күбрәк татарлар тарафыннан "Әйдә, нитәбез!" – дигән формада, ничек аңлыйсың килә шулай кабул ителә. Ягъни "нитеп" яшибез.

Казан урыслары җөмлә ахрына "да"ны өстәп куймасалар канәгать калмыйлар. Мәсәлән: "Этот автобус идет до вокзала, да?" Ә татарлары әлеге сорауны болайрак тәмамлый: "Бу автобус вокзалга хәтле барадырыемы?"

Әгәр сиңа кемгә булса да нинди нәрсәнең кайда икәнен аңлатырга туры килсә, ике вариант бар: дөресе һәм казанчасы. Дөресе: "Возле "Бәхетле" на Амирхана есть "Макдоналдс". Казанчасы "На Амирхана есть же "Бәхетле". Вот возле него, считай, рядом "Макдоналдс".

Менә шундый үзенчәлекле безнең казанлыларның сөйләм теле.

Өстәп әйтәсе килә: "Земляки, айдате-ка, говорить правильно! Чай, в столице живем. Считай, пора уж, да? Без булдырабыз!

Виталий ФЕОКТИСТОВ



Эрнест ДЫШАЕВ



Виктор ФЁДОРОВ



Николай ВОРОНЦОВ





ПОГОНЛЫ КАРАК

Дәүләт юл хәрәкәте инспекциясендә коррупциягә каршы көрәш үзенең нәтиҗәләрен китерә башлады шикелле. Ләкин нәтиҗәләр һич тә көтелмәгән яктан килде. Күптән түгел Казанда юл инспекторы Дмитрий Сироткинга карата хөкем карары чыгарылды. Узган елның ахырында ул супермаркетта... бер "таяк" колбаса урлаган. 20 ел буе юл сагында торган инспекторны нинди шайтан котырткандыр – бу билгеле түгел. Бәлки, эчке эшләр министрлыгында башланган коррупциягә каршы көрәш нәтиҗәсендә керемнәре кимүдер... Бернәрсәгә карамастан, суд бу гамәлне җинаять дип тапты, һәм инспекторга җәза итеп, 120 сәгать иҗтимагый эшләр билгеләде.

СӨЙЛӘШМӘГӘН ӨЧЕН... ТҮЛӘҮ

Кризис шартларында һәркем булдыра алганча бөтерелә. Мәсәлән, кәрәзле элемтә операторлары... күрсәтмәгән хезмәт өчен акча алырга булганнар. Хәзер, әгәр абонент сөйләшми, смс җибәрми һәм номерыннан Интернетка чыкмый икән, билгеләнгән вакыт үткәннән соң, аның счётыннан "элемтә хезмәтеннән файдаланмаган өчен" көненә 15 сум алына. Ачулары чыккан абонентлар ачык алдауга каршы имзалар җыю оештырганнар. Кем белә бит, бәлки, елгыр телефончыларга карап, кибетләр дә шул ук юлдан китәргә теләк белдерер: килдең, берни дә сатып алмадың – "сәүдә хезмәте белән файдаланмаган өчен" акчаңны чыгарып сал.

"АЛТЫН ПОРОШОК" ОПЕРАЦИЯСЕ

Камчатка краеның Вилючинск шәһәрендә яшәүче берәүгә парацетамол саткан өчен... ике елга иректән мәхрүм итү яный. Барысы да егетне наркотиклар белән сәүдә итүдә шикләнүдән башланган. Ләкин махсус орган хезмәткәрләре контроль сатып алу ясаганда, өч мең сумга сатылган ак порошок гади температура төшерүче дару – парацетамол булып чыккан. Кәефләре кырылган контролёрлар егетне мошенничествода гаепләгәннәр. Ә тегесе, үз чиратында, бары тик парацетамол белән сәүдә итүе турында белдерә. Ә бәянең югары булуын таблеткаларны уып, аны төргәкләүгә күп хезмәт куюы белән аңлата.



Тимер БУЛАТОВ

МИЛЛИОНЫНЧЫ САТЫП АЛУЧЫ

Супермаркет директоры Кәкәев ашыгыч рәвештә каравыл башлыгын үзенә чакыртты.

– Синең бездельникларың бөтен кроссвордларны да чишеп бетерделәрме әле? – дип башлады ул сүзен, көтмәгәндә.

– Юк әле, Гали Галиевич! – диде аңа отставкага чыккан прапорщигы.

– Шулайдыр шул, күренеп тора! Ә син беләсеңме безнең супермаркет тирәсендә ниләр мәтәштергәннәрен?

– Әйтә алмыйм! Ә нәрсә?

– Күзләреңне ачып йөр! Кибет кырыенда инде ярты еллап ниндидер бәндә чуала, һәм нәрсәдер язгалап ала... Көне буе синең борын астында йөри бит ул шулай...

– Кит аннан, моның булуы мөмкин түгел! Бу тирәдәге барлык сәрхушләрне һәм теләнчеләрне беләм бит мин!

– Болай итәсең! Ачыкла, кем ул һәм нәрсә яза! Бәлки ул супермаркетта талау оештырырга маташа... Уңышларыбыздан көнләшүчеләрнең дә этлек эшләргә җыенулары мөмкин... Шуннан да начаррак хәлләр китереп чыгармасыннар тагын, әйтик, салым органнары яшерен күзәтү оештырмадылар микән... Аңладыңмы?!

– Һичшиксез! – дип, каравыл башлыгы хәрбиләрчә сандалларын бер-берсенә бәреп, шакылдатып куйды.

Кич җитүгә ул приказның үтәлүен белдерде.

– Гали Галиевич, бар нәрсәне ачыкладык! Әлеге мужик иртәдән кичкә кадәр супермаркетка килгән сатып алучыларны саный икән...

– Ни өчен?

– Без бит миллионынчы сатып алучыга приз – автомобиль вәгъдә иткән идек. Ул менә үзен шул санга туры килеп булмас микән дип, кеше санын чутлый.

– Ә-ә-ә... – диде дә Кәкәев, тынычланды. – Санасын, бүтән эше булмаса...

“Ул бит, мескен, белми, – дип уйлады директор, – инде миллионынчы сатып алучы итеп аның кайнанасы билгеләнгәнен...”



Виктор ФЁДОРОВ



Валерий ТАРАСЕНКО

Рашат НИЗАМИ

ҺӘЙКӘЛ

Шаккатамын һәм тел шартлатамын:
Район саен – танк һәйкәле.
Нигә, нигә трактор дустыбызга
Һәйкәлләр юк – шуны әйт әле!..

ДОЛЛАР

Рубльне яратучы сирәк,
Бик күпләрне доллар кол итә.
Ач күзеңне! Шушы яшел кәгазь
Күп илләрне тузан, көл итә.

ХАКЕР

Акыл-хәйлә белән коралланып,
Зур мәйданга чыкты хакерлар.
“Эһ!” тә итми генә компьютерның
Ишек-тәрәзәсен шакыйлар...

БӘДДОГА

Халыкара рингта –
сугыш... кара сөрем...
Ник ашкынмый илләр яктыга?
Канлы сугыш генералларына,
Бомбаларга – бездән бәддога!

ТЕЛӘК

Сугыш чукмарларына мин
Зур сугыш башлар идем, –
Крокодиллар мыжгып торган
Елгага ташлар идем!

Ләбиб ЛЕРОН

ШАГЫЙРЬ, ИЛЛЕ ТӘҢКӘ ҺӘМ... ТӘНКЫЙТЬЧЕ

Мөдәррис Әгъләмнең университет шәкерте булып саналып йөргән чагы икән.

Университетка баргалап-кайткалаган өчен бирелгән стипендия акчасының язмышын икеөч көндә хәл иткәч, Мөдәррис Әгъләм, өстенә тоз сибелгән ипи катысын авызында җебетәҗебетә, стаканыннан Мәскәү Кремле күренеп торган чәен эчкән вакытта, берәр студенттан әҗәткә акча сорап торырга уйлаган...

Менә коридорның бер башында Мамадыш егете, ике Мөдәррис буйлык Ринат Мөхәммәдиев дигән студент пәйда булган.

Шигъри хәрәкәтле адымнар белән Мөдәррис аның каршына чыга да:

– Карале, Чаллыдагы апаның туган көне иде. Котлап телеграмма сугарга акча җитми. Стипендия алганга кадәр илле тәңкә биреп тор! – ди.

Ринат Мөхәммәдиевнең каядыр ашыга торган чагы булгандыр инде, ул Мөдәррискә иелеп карый да кесәсеннән акча чыгара. Тиешле сумманы санагач:

– Телеграммага ике сум гына җитә түгелме соң? – дип сорап куя. Мөдәррис акчаны җәһәт кенә үрелеп ала да, бүтән төпченмәслек итеп:

– Мин телеграмманы җизнигә дә сугам! – ди...

Көннәр, айлар уза. Көне-төне шигырь язып яткан җиреннән аерылып, ике тапкыр стипендия акчасы алып кайта Мөдәррис. Ринат Мөхәммәдиев тә ике тапкыр аның бүлмәсенә кереп хәлен белеп чыга. Ләкин икесендә дә Мөдәрриснең хәле мактанырлык булмый.

– Әле генә Зәйдәге абыйның хатынының энесенең әтисенә телеграмма суктым. Юбилее иде. Кесәдә ике сум егерме җиде тиен генә акчам калды. Стипендия алгач кайтарырмын, – ди Мөдәррис...

Тагын көннәр уза. Мөдәррис Әгъләмнең кайсыдыр гәҗиттә бер бәйләм шигырьләре дөнья күрә. Ринат Мөхәммәдиевнең, ниһаять, түземлеге төкәнә.

– Ыслуш-шай, Мөдәррис, – ди ул шул көнне, – илле сумны бирергә уйлыйсыңмы син, юкмы? – һәм иелеп, сыңар кулы белән шагыйрьне үз буе озынлыгына кадәр күтәреп ала.


– Нинди илле сум тагы? – ди Мөдәррис, бик нык гаҗәпләнеп. – Инде ничә тапкыр нинди дер акча сорап тинтерәтәсең. Шагыйрь бит мин. Акча ясаучы түгел. Вакытың булса, менә минем шигырьләрне укы, өйрән!

Һәм ул үзенең шигырьләре басылган гәҗитне Ринат Мөхәммәдиевнең зур акча янчыгы хәтле кулына тоттыра да, идәнгә сикереп төшеп, тиз-тиз генә китеп бара...

Күп тә үтми, матбугат битләрендә тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиевнең исеме күренә башлый.

Аның тәүге тәнкыйть язмаларының берсе Мөдәррис Әгъләм шигырьләре турында иде, дип сөйлиләр...

Вячеслав ШИЛОВ



Николай ГЕРГЕЛЬ





ТИШЕК КОПЧӘК

Антон МАКУНИ

КАРА СИН АНЫ!..

Күҗәев үзенең күпне күргән иске «Жигули»енда әкрен генә иң уң рәттә бара иде. Кайтып җитәргә инде күп тә калмаган иде, тик юл янында кул күтәргән озын плащ бөркәнгән ир кешене күреп алды. Күҗәев машинасын туктатты. Ир кеше, сорап-нитеп тормастан, алгы утыргычка түнде, һәм тирән сулап:

– Дус кеше, өч тукталыш кына, эшкә соңга калам, – диде.

«Нигә кешегә ярдәм итмәскә? – дип уйлап куйды Күҗәев. – Бәлки, әзрәк акча да бирер – бензинга хәзер күп китә бит».

Кузгалып киттеләр. Ир кеше, Күҗәевкә таба борылып, зур кызыксыну белән аның ничек итеп машина йөрткәнен күзәтә башлады.

– Күптәннән өйрәнәсем килә, тик вакыт җитми. Бу мәнә нәрсә? – Ир кеше идарә итү панеленә төртеп күрсәтте.

– Бу спидометр, тизлекне күрсәтә, – диде Күҗәев горурлык белән, аз булса да үзен инструктор итеп тоеп.

– Кара син аны! – пассажирның күңеле күтәрелде. – Спидометр... Ә бу нинди тотка?

– Кул тормозы, гади итеп әйтсәк, «ручник», – дип аңлатты Күҗәев.

– Кара син аны, ручник! – Ир кеше тел шартлатып куйды. – Ул машинаны туктата, шулай бит?

– Әйе, гадәттән тыш очракларда аның белән дә туктатырга була, тик аның өчен тормоз педале бар, – Күҗәев бер кулын рульдән алды һәм аяк аска төртеп күрсәтте.

– Кара син аны, – дип башын селкеде юлдаш, – аңладым! Ә алай булгач, газ кайда?

– Ә газ уң якта, – дип аңлата башлады Күҗәев, тулысынча инструктор роленә кереп. – Менә мин газга басам, һәм машина тизрәк бара...

– Исең китәр! – дип шатланды ир кеше. – Кара, чынлап та тизрәк бит! Ә ул тагын да тизрәк бара аламы?

Җавап итеп Күҗәев авыз чите белән елмайды да, көчле итеп педальгә басты. Машина, үкереп, алга ыргылды.

– Кара син аны, ә! – диде ир кеше, кул чабып. – Искиткеч! Ә хәзер туктагыз! – Шул вакытта ул җилкәсеннән плащын салып җибәрде. Аның астыннан шомлы ялтырап, юл инспекторы билгесе тагылган форма килеп чыкты.

– Өлкән Хәбибуллин, – диде ул югалып калган йөртүчегә. – Кагыйдә бозасыз! Права һәм техпаспортыгызны күрсәтегез!

– Соң сез үзегез... – дип аклана башлады Күҗәев, документларын сузып. – Сез үзегез... куштыгыз бит...

Сез нәрсә, иптәш, тизлекне чикләү билгесен күрмәдегезмени? – дип сорады кырыс кына лейтенант. – Барыбер штраф түләргә туры киләчәк.



Вячеслав БИБИШЕВ



Илдар НӘФИЕВ



Сергей ЕРМИЛОВ



Александр КОСМЫЛИН



Николай ВОРОНЦОВ



ҖИЛ ОЧЫРТКАНДА

Кадерле Чаян! Чехов базарында шундый гаҗәеп табигать халәтенең шаһиты булырга туры килде миңа. Ял көннәрендә уза торган ярминкәгә килсәм – атланмайга куелган бәя һәм нинди продукт икәнен аңлаткан язулар юкка чыккан. Элек бар иде, ә хәзер – юк! Әлеге бәяләр кая китте икән дип кызыксына башладым. Сатучылар җавабына караганда, җил очырган икән. Менә сиңа тамаша... Ничек итеп җил өере башка бәянамәләргә кагылмый, атланмайныкын гына очыртты икән соң? Дөрес, бер сатучының бәянамәсен җил түгел, ә сатып алучы алып киткән икән. Бик кирәк булгандыр инде аңа базарда таушалып беткән кәгазь кисәге... Менә шундый сәер табигать күренеше дөреслекне генә исбатлый.

Ә дөреслеккә килгәндә, инде бик күптән әлеге базар аномалияләрен тикшерергә вакыт. Бигрәк тә вазыйфасы буенча тиешле тикшерүчеләр кызыксынсалар... Менә алар әйтер иде инде, кемне нинди җил очыртып алып килгәнен әлеге базарга.

А. ГАРИПОВА

КАЗАН

САК БУЛЫГЫЗ, БАЛАЛАР!

Хөрмәтле редакция! Фатир сатып алучылар сатыла торган фатир карамагында балигъ булмаган балалар булмавын кулайрак күрүләре беркемгә дә сер түгел. Чөнки опека органнары вәкилләреннән сатуга ризалык алу бик җиңел эш түгел.

Ел башында мин бер бүлмәле фатирымны ике бүлмәлегә алыштырырга уйладым. Без кызым белән икәү генә яшибез. Кызыма да аерым бүлмә булдырасы килү сәбәпле, сатып алучыны да таптым. Ул бераз көтәргә ризалашты. Бик күп мәшәкатьләрдән соң, балалар яклау органыннан рөхсәт алдым. Хәзер исә хыялым чынга аша дип сөендем. Юк икән шул! Узган ел ахырында балигъ булмаган балалары булган әти-әнигә, бөтен алыш-биреше нотариус белән килешү кәгазе төзергә дигән яңа канун чыккан икән. Әлбәттә, балаларның хокукын яклауның тагын бер ысулы бу.

Нотариуска килдем. Минем кәгазьгә кул куяр өчен бер ай алдан язылаcы, әллә ничә чират үтәсе, 26 (!) мең сум түлисе икән. Нәрсә өчен шуның кадәр акча түлисе, нотариаль кәгазь төзегән өченме?

Бик тырышлык белән тапкан сатып алучым мәшәкатьләр белән чапканымны көтем тора алмады. Күрәсең, җайлырак вариант тапты. Кызыма үз бүлмәсе булган фатир алу бәхетенә дә ирешә алмадым. Бу очракта дәүләт кемне яклады соң? Минем баламнымы, әллә опека органнары һәм регистрация палатасының кәгазьләрен дублировать иткән нотариусныимы?

О. МАЛАШИНА

КАЗАН

Алмаз ХӘМЗИН

БЕР ХАТИРӘ

Хәтерләмим... Ничә яшьтә булдым икән мин ул чакта? Алтынчы, җиденче сыйныфларда укыганмындыр, мөгаен... Күрше авыл Шаңгәлчедә зур концерт була дигән хәбәр иртүк яшен тизлеге белән халык арасында таралды. Бармыймны соң инде – үзеңнән түлисе түгел, колхоздан, ди. Артистлар машина әрҗәсе өстендә җырлаячаклар икән. Менә бәхет! Мин әти-әниемә барасы килүемне белдердем. Ә алар миңа – рас!.. Кыр бакчасындагы бәрәңгенең чүп үләннәрен утап бетермичә җибәрмибез, диләр. Нишлисең?.. Бармыйсың, дип әйтмәделәр ич. Китмәнемне алып кырга йөгердем. Ярсып эшлим – өлгерергә кирәк.

Җәй кояшы иртәнрәк сүрән булса да, әкренләп, төшкә таба башны кыздыра башлады. Чыдыйм. Тамак чылатырга булса да су алмаганмын. Кипкән иреннәремне ялап кына хәлгә килеп булмый шул. Нишләргә инде? Кайтып килми ярамас, дип уйлап, китмәнемне иң өстемә салдым гына, тыкрыктан бер абыйның иң өстенә башын салган апа, җырлап, безнең бәрәңгелек яныннан үтә торган юлдан атлый. Мин мондый күренешне һинд киноларында гына күргәнем бар иде. Җыры шундый матур:

...Айлы төн йолдызлы –
Йоклый гөлләр,
Кошлар тынып калган,
Ә мин йоклый алмыйм...
Сине көтәм һаман.

Мин, эшләгән булып, буразна буйлап боларга таба атлыйм. Шулчак әлеге апа, җырыннан бүленеп, минем янга килде дә:

– Үскәнем, башыңа кызу каба күрмәсен, берәр нәрсә ки яисә өеңә кайт, эш качмас, – дип, чәчемнән сыйпап китеп барды.

Кич белән карыйм, сәхнәдә җырлаган апа, шул минем белән сөйләшкән кеше – Әлфия Афзалова икән бит. Күзләрем шар булды. Ә тегесе – аның белән бергә җиде чакрым ераклыктагы Чапчак авылыннан безнең тыкрык аша Шаңгәлчегә җәү концерт куярга баручысы Илһам Шакиров булып чыкты.

Еллар үткәч, Әлфия апа миңа сокланып:

– Әй, кайлардан шундый Кеше булып пәйдәләндең син?! – дип әйткәли башлады.


– Әлфия ханым, менә син кечкенә чагымда башымнан сыйпап үткән идең, шуннан соң, пеләшләнеп, шулай булып калдым инде! – диеп җавап бирә торган идем, шаяртып. – Хәзер, – мәйтәм, – чәч тә юк, китмән тотарга да хәл калмаган, урамдагы талгын җилгә каршы барырдай көч тә чамалы гына.

– Син яшь әле, менә минем хәтле яшәсәң ни диярсең?

– Уфтана да алмас идем.

– Беркайчан да уфтанма, җанкай, син дөрес яшисең, халык үзеңне бик ярата!

Мин аңа бик озак сокланып карап тордым. Инде кечерәеп калган гәүдәсенә нинди бөеклек сыйган! Күпме кодрәтле, мәрхәмәтле моңлы җырлар тудырган шушы апа! Һаман илаһи җылылык, күркәмлек, наз бөркелә аннан! Даһилар симфониясе синең тормышың, Әлфия ханым! Син атылган метеорит кебек һавада янмадың. Син – бәгырьләрдән сузылып чыктың да, җиһанга атылып, милләтебез күгендә мәңге сүнмәс йолдыз булып балкып торасың!



Иван ХАНТИМЕРОВ, «Чаян» № 22, 1980

– Һава, тизрәк кыймылда! Соңга калабыз!



Виктор ИГНАТЬЕВ, «Чаян» № 16, 1962

АПРЕЛЬДӘ БЕРКЕМГӘ ДӘ ЫШАНМА!

Эльвира ДЫШАЕВА



Александр АЛЁШИН



Ринат БӘШИРОВ



ШАЯРТМЫЙБЫЗ-КӨЛМИБЕЗ

ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

Хәбәр итәбез: икенче яртыеллыктан башлап «Чаян» ике тапкыр калынрак булып чыга башлаячак. Ике санны бергә кушып, журналны айга бер тапкыр чыгарырга карар кылынды. Айлык «Чаян» элеккечә сезнең тугры шаян дустыгыз булып калыр дип өметләнәбез!

Яңартылган «Чаян»га быелның 1 апреленнән үк язылырга була (бу шаярту түгел!).

Ә хәзер игътибар! Яраткан журналыгызны катлаулыкларсыз алыр өчен язылу тәртибендәге үзгәрешләргә игътибар итегез.

Татарстан укучылары аны «Почта России» каталогы, шулай ук онлайн https://podpiska.pochta.ru аша эшли алалар.

Бу очракта язылу индекслары татарча журналга П2438, ә русчасына П2440 булачак.

ОАО «Агентство «Роспечать» каталогында язылу индекслары элеккечә калды: 73488 – татар телендә, 73489 – рус телендә. Аның буенча Россия һәм Татарстан укучылары языла ала.

«Чаян» өегезгә кояш булып керсен!

ЧуАр пресса

БЕНДЕР БУЕНЧА

Сочидагы бер пансионатта берничә иске урындык юкка чыккан. Директор полициягә мөрәҗәгать итеп тормаган, каракны үзе эзләргә тотынган. Моның белән ул полицейскийларны шаккаттырган.

Озакламый, детектор ярдәмендә, урындыкларның берсесен каравылчы үзенең бакчасына алып киткәне ачыкланган. Урындыкның ни дәрәҗәдә кыйммәт булуын ул күз алдына да китерә алмаган. Ильф һәм Петров геройларының мисалына карап, директор урындыкка 100 мең евро яшергән була. Үз чиратында директорны детекторда тикшерәчәкләрме, юкмы – әлегә билгесез.

ГИННЕССКА ТАБА

Гомельдә яшәүче Владимир Борщов Гиннеслар рекорды китабына эләгергә хокуклы. 2008 елны ул тотылган "Пежо" машинасы сатып алган һәм шул вакыттан бирле 55 тапкыр юл һәлакәтенә эләккән. Аны талаганнар, стоянкада кыйнаганнар, бәргәннәр һәм кырганнар. Шунысы гаҗәп – ДТПның берсесендә дә Владимир үзе гаепле түгел. Көчкә-көчкә булса да, һәлакәтләр исәбен тутыра-тутыра һәм страховой компанияләрне борчып булса да, машина йөреп тора.

ХАТАНЫҢ БӘЯСЕ


Хакерлар Нью-Йоркның Федераль резерв банкның системасын ватып ачканнар һәм бер счеттан икенчесенә 80 миллион доллар күчергәннәр. Тик икенче транш барып чыкмаган. Банк хезмәткәрләрен запростагы орфографик хата шикләндергән. Банкирларның яхшы укый-яза белгәнлеге һәм хакерларның наданлыгы 80 миллион доллар урлауны булдырмый калган. Мәктәптә яхшы уку өчен тагын бер сәбәп барлыкка килгән.



Гордон КУЛХАРТ (Англия)



Ги РОДД (Бельгия)




КОВЕРЛИ





ГИ и РОДД (Бельгия)



Марек ДУДКА (Польша)



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

– Сез нинди дә булса дару эчәсезме?

– Юк.

– Шулай булгач, үзегезнең спорттагы уңышларыгызны ничек аңлатып бирә аласыз?

– Мин күп итеп ботка ашыйм.

– Аңлашылды. Димәк, безгә ботканы WADA допинг исемлегенә кертергә кирәк.

• • •

Чүтеки дөньяда дөреслек бар. Көн саен иртүк перфоратор тавышы белән безгә йокы бирмичә, ярты ел буе интектереп ремонт ясаган күршегә, эшләре бетү белән, тещалары күчеп килде.

• • •

– Кичә мин бер ачыш ясадым: Пушкин шигырьләр язмаган икән!

– Алай булгач, каян алган соң ул аларны?

– Интернеттан күчергән!

– Ничек шундый нәтиҗә ясыйсың?

– Кичә Интернетта утырдым, ә анда Пушкин китабында язылган шигырьләр – муеннан!

• • •

Төзелештә. Бригадир янына, куркыбрак, яңа гына эшкә алынган егет килә:

– Мин, уйлавымча, ялгышлык җибәрдем. Проводканы оныткан-мын...

Моңа прораб җитди генә җавап бирә:

– Исеңдә тот, егет: без монда “про водка” турында беркайчан да онытмыйбыз!

• • •

– Доктор, миңа сезнең даруыгыз бик килеште!

– Нәрсә дип әйтим? Булгалый!

• • •

Менә телевизордан акыралар: “Шампунь “Ат көче” – чәчне күз алдында үстерә!” Аңлый алмыйм – күз алдымда миңа чәч нигә?





САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ

№ 1 2016

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры һәм баш редактор
Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ

Баш редактор урынбасары: **Ринат АБЗАЛОВ**
Баш редактор урынбасары, баш рәссам: **Александр АЛЁШИН**
Үсеш бүлеге: **Әдилә БАҺАВЕТДИНОВА**
Марс САБИРОВ
Җаваплы секретарь: **Гөлнара ЗАМАЛДЫНОВА**
Бүлек редакторлары: **Людмила САФИУЛЛИНА**
Артём СУББОТКИН
Алмаз ХӘМЗИН
Лилия ӘХМӘТОВА
Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: **Ләйсән ФӘЛӘХОВА**

УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итүче Федераль служба (Роскомнадзор) идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
Эл № ФС77-61789, 18 май, 2015 ел.
Нәшер итүче: **АО «ТАТМЕДИА»**
Адрес: 420047 Казан, Академическая ур., 2
Редакция фикере авторлар фикере белән тәңгәл килергә мөмкин.
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-тәзәтү хокукына ия.
Реклама белдерүләренең дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.
Басма 16 яшьтән өлкәнрәк укучылар өчен чыгарыла.
«Чаян»нан икенен күрсәтмичә журнал әсәрләрен файдалану тыела.



Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00,
тел./факс: 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan.su


16+

Редакциянең адресы: Декабристлар ур., 2, ТР, Казан, 420066

ЧАЯНВОРД

Уйна да, уйла да!

Ринат АБЗАЛОВ төзеде.



Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда ике җыр исемнәрен укыгыз. Журналыбызның 5 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзләре – **«КЫЗЫЛ ТӨЛКЕ», «ДИСӘНӘ».**


Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:
Р. ЗАҺРИЕВ (Кукмара р-ны, Югары Арбаш ав.),
Р. ЙОСЫПОВ (Арча р-ны, Яңа Кишет ав.),
М. МИҢНЕМУЛЛИНА (Балтач р-ны, Норма ав.),
Ф. САБИТОВА (Яшел Үзән р-ны, Күгеш ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Күгеш авылыннан
Фәнзия САБИТОВА!

Безнең бәя үзгәрергә иренә

- Цифралы ТВ
  Мультирум хезмәте белән
- Өй Интернеты


550 ₽ аена



МТС

dom.mts.ru | 8 800 250 00 50






ТВ

Күрсәтелгән шартлар буенча ялгану срогы 29.02.2016дан 31.05.2016га кадәр. "Мультирум" хезмәте 2 нче телевизорга ялгану көненнән башлап 12 ай дәвамында бирелә. ТВ җиһазларының һәм Wi-Fi роутерының бер берәмлеге өчен аренда түләве айлык тариф түләвенә кертелгән. Җиһазның икенче комплекты стандарт аренда түләвенә бирелә. Күрсәтелгән шартлар яңа абонентлар өчен каралган. Цифралы МТС ТВның гамәлдәге абонентлары махсус шартлардан "Өй Интернеты" хезмәтенә ялганган очракта файдалана алалар. Тулы мәгълүмат — www.mts.ru битендә.

Реклама буларак бирелә

ЭРДОГАН (Төркия)

Соңгы вакытта Төркиядә ЭРДОГАН фамилиясе бик еш яңгырый башлады. Бәхеткә каршы, бер кеше – ул әле бөтен ил түгел. Моның ачык мисалы – Истанбул карикатурачысы Эрдоган. Аның безнең редакциягә бүләк иткән рәсемнәре планетаның танылган карикатура осталары белән таныштыра торган сәхифәбезне дәвам итә.









4 612750 670080